| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 6 КАРАР

12 ноябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Кормаш авылында 2026 елга үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы нигезендә. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставы:

1.Кормаш авылы Үзәк урамында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 18 ноябренә 9 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын 1000 сум куләмендә кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
-Кормаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу)?»
«ӘЙЕ» ЮК".
3.Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгының «2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Кормаш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турындагы "05.11.2025 ел, № 3 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Кормаш авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина